# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $8^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1статья**

“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктындагы унберенче абзацта “хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге” сүзләреннән соң “, онкология авырулары” сүзләрен өстәргә;

2) $8^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$8^1$статья. **Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге, онкология авырулары белән авыручы затларга социаль ярдәм чаралары**

1. Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.

2. Онкология авырулары белән авыручы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтә торган Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендәге дәвалану

урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәли көче 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 20 мае
№ 37-ТРЗ